СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
**06.03.2017**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 174**

Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль милкендә булган җир кишәрлекләре белән яңадан бүлү нәтиҗәсендә хосусый милектәге җир кишәрлекләре мәйданын арттыру өчен түләү күләмен билгеләү тәртибен раслау турында

«Зеленодольск муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль учреждениесе җитәкчесе Н.В.Гусевның Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль милкендә булган җир кишәрлекләре белән аларны яңадан бүлү нәтиҗәсендә хосусый милектәге җир кишәрлекләре мәйданын арттыру өчен түләү күләмен билгеләү тәртибен раслау турында мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.28 статьясының 5 пункты нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. Татарстан Республикасы “Зеленодольск муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең муниципаль милкендә булган җир кишәрлекләре белән яңадан бүлешү нәтиҗәсендә хосусый милектәге җир кишәрлекләре мәйданын арттыру өчен түләү күләмен билгеләү тәртибен расларга (кушымта итеп бирелә).
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә урнаштырырга.

**Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы,**
**Совет рәисе** **А. В. Тыгин**

Зеленодольск муниципаль районы Советының
2017 елның 6 мартындагы 174 карарына кушымта

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ МУНИЦИПАЛЬ МИЛКЕНДӘ БУЛГАН ҖИР КИШӘРЛЕКЛӘРЕ БЕЛӘН АЛАРНЫ ЯҢАДАН БҮЛҮ НӘТИҖӘСЕНДӘ ХОСУСЫЙ МИЛЕКТӘГЕ ҖИР КИШӘРЛЕКЛӘРЕ МӘЙДАННАРЫ АРТТЫРУ ӨЧЕН ТҮЛӘҮ КҮЛӘМЕН БИЛГЕЛӘҮ**
**ТӘРТИБЕ**

1. Әлеге тәртип Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль милкендә булган җир кишәрлекләре белән яңадан бүлү нәтиҗәсендә хосусый милектәге җир кишәрлекләре мәйданын арттыру өчен түләү күләмен билгеләү кагыйдәләрен билгели.

2. " Зеленодольск муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы" муниципаль учреждениесе тарафыннан түләү күләме исәпләнә.

3. Түләү күләме формула буенча исәпләнә:

Рп = УПКСчс х (Sобрчс - Sисхчс),
кайда:

Рп-түләү күләме;

УПКСчс - хосусый милектә булган җир кишәрлеге өчен кадастр бәясенең чагыштырма күрсәткече, аның мәйданы яңадан бүлү нәтиҗәсендә арта, ул күчемсез мөлкәт объектының мәйданы берәмлегенә исәпләгәндә кадастр бәясен чагылдыра (сум/кв. м);

Sисххчс- яңадан бүлүгә кадәр, хосусый милектә булган башлангыч кишәрлекнең мәйданы,

Sобрчс – хосусый милектә булган яңа төзелгән җир кишәрлегенең яңадан бүлү турындагы килешү нигезендә урнашкан мәйданы;

4. Җир кишәрлекләре муниципаль ихтыяҗлар өчен төзелергә тиешле җир кишәрлекләрен алга таба тартып алу максатларында яңадан бүлгән очракта, түләү күләме Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль милкендә булган җир кишәрлегенең җир кишәрлекләрен яңадан бүлү нәтиҗәсендә хосусый милеккә тапшырылырга тиешле өлешенең базар бәясенең бәяләү эшчәнлеге турындагы законнар

нигезендә билгеләнә.